МИНИСТЕРСТВО
ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
УПРАВЛЕНИЯ,
ИНФОРМАЦИОННЫХ
ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН
ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ
ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ
ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.10.2025 Казан ш. № п/288

Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 100 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү тәртибен (алга таба – Тәртип).

Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү буенча комиссия турында нигезләмә.

Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү буенча комиссия составы.

2. ИТ-бергәлекне үстерү секторына (М.Р.Кармановага):

расланган Тәртип нигезендә урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрүне тәэмин итәргә;

әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга: https://digital.tatarstan.ru/.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Б.Ф.Габдрахмановка йөкләргә.

Министр И.С.Начвин

Татарстан Республикасы Дәүләт
идарәсен цифрлы нигездә үстерү,
мәгълүмат технологияләре һәм элемтә
министрлыгының 23.10.2025 ел,
№ п/288 боерыгы белән расланды

Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү тәртибе

1. Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс уздыруның әлеге Тәртибе урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс уздыру кагыйдәләрен билгели (алга таба, тиешенчә – конкурс, белем бирү оешмасы, кабул итүнең контроль саннары, уку-укыту программалары).

2. Кабул итүнең контроль саннары конкурс сайлап алулары барышында бүленә, алар ел саен 30 гыйнварга кадәр үткәрелә торган конкурсның төп турыннан һәм, әлеге Тәртипнең 28 пунктында каралган очракларда, 30 мартка кадәр үткәрелә торган конкурсның кабул итүнең контроль саннары билгеләнә торган өстәмә турыннан тора.

Конкурс сайлап алулары ел саен Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан үткәрелә.

3. Кабул итүнең контроль саннары урта һөнәри белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булган һәм булмаган уку-укыту программалары буенча бүленә.

4. Кабул итүнең контроль саннары урта һөнәри белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булмаган уку-укыту программалары буенча укыту өчен бары тик күрсәтелгән уку-укыту программалары буенча дәүләт аккредитациясе элек үткәрелмәгән очракта гына һәм белем бирү оешмасы күрсәтелгән белем бирү программалары буенча дәүләт аккредитациясен алу йөкләмәсен кабул итүнең контроль саннарын билгеләгән вакыттан алып ике ел эчендә, ләкин кабул итүнең билгеләнгән контроль саннары чикләрендә укырга кабул ителгән укучыларны укытуны тәмамлаганчыга кадәр генә, үтәгән очракта бүленә.

5. Конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча кабул итүнең

контроль саннарын бүлү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – Конкурс комиссиясе) тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның составы һәм нигезләмәсе Министрлык боерыгы белән раслана.

6. Конкурс уздыру өчен Министрлык үзенең рәсми сайтында гаризалар кабул итү көненә кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, әмма 28 ноябрьдән дә соңга калмыйча, конкурс турында белдерү урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

конкурсны үткәрү көне, вакыты һәм урыны;

кабул итүне тәмамлау датасы 10 декабрьдән дә соңга калмыйча билгеләнә торган белем бирү оешмаларының гаризаларын кабул итү сроклары;

конкурсны уздыруның максаты;

кабул итүнең конкурс үткәрү барышында бүленә торган контроль саннарының гомуми күләмнәре;

һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, урта һөнәри белем бирү белгечлекләренең эреләндерелгән төркемнәре буенча белем бирү оешмасы конкурсы нәтиҗәләре буенча билгеләнергә мөмкин булган кабул итүнең контроль саннарының минималь күләме;

конкурста катнашучыларга карата таләпләр;

гаризаның эчтәлегенә һәм аны рәсмиләштерүгә карата таләпләр;

һәр күрсәткечне бәяләү критерийларын күрсәтеп һәм һәр күрсәткеч буенча баллар санын билгеләп, белем бирү оешмасы эшчәнлегенең төп күрсәткечләре исемлеге;

гаризаларны кабул итә башлау һәм тәмамлау көне, вакыты һәм урыны;

конкурс комиссиясе тарафыннан гаризалар белән конвертларны ачу көне һәм вакыты;

конкурс гаризаларын карау һәм бәяләү процедурасы;

конкурс нәтиҗәләрен игълан итү вакыты һәм ысулы:

уку елына конкурс нәтиҗәләре буенча кабул итүнең контроль саннарын билгеләү турында Министрлык боерыгын чыгару срогы.

7. Белем бирү оешмалары әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы өченче абзацы нигезендә билгеләнә торган срокта мөһерләнгән конвертларда кәгазь документ рәвешендә конкурста катнашуга гаризалар (алга таба – конкурс гаризалары) бирәләр. Бер белем бирү оешмасыннан бары тик бер генә конкурс гаризасы бирелергә мөмкин, ул әлеге Тәртипнең 28-33 пунктларында каралган конкурсның өстәмә турын уздыру барышында тулыландырыла ала.

8. Белем бирү оешмасының конкурс гаризасында түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) белем бирү оешмасының исеме, оештыру-хокукый рәвеше, урнашу урыны һәм почта адресы турында белешмәләр;

б) чираттагы уку елына кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча белем бирү оешмасының төп эш бирүчесе белән килештерелгән тәкъдимнәре («Профессионалитет» федераль проектында катнашкан очракта);

в) тиешле һөнәрләр, белгечлекләр буенча урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга белем бирү оешмасының лицензиясе булуы турында белешмәләр;

г) белем бирү оешмасының тиешле һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча урта һөнәри

белем бирүнең уку-укыту программалары буенча дәүләт аккредитациясе булуы турында белешмәләр (булган очракта);

д) урта һөнәри белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булмаган уку-укыту программалары буенча укыту өчен кабул итүнең контроль саннары билгеләнгәннән соң ике ел эчендә, әмма кабул итүнең билгеләнгән контроль саннары чикләрендә укырга кабул ителгән укучыларны укытуны тәмамланганчыга кадәр генә, белем бирү оешмасының һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча дәүләт аккредитациясен алу йөкләмәсе (әгәр белем бирү оешмасы гаризасында дәүләт аккредитациясе булмаган уку-укыту программалары буенча кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча тәкъдимнәр булса);

е) конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру барышында бәяләнә торган белем бирү оешмасы эшчәнлеге күрсәткечләренең мәгънәләре;

ж) эш бирүчеләрнең игълан ителгән һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең һәм белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча кадрлар әзерләүгә заказы белән белем бирү программасы юнәлеше буенча һөнәри квалификацияләр советларының региональ вәкиллекләре белән килештерелгән гаризалары (булган очракта);

з) белем бирү оешмасын гамәлгә куючының имзасы һәм мөһере белән (булган очракта) таныкланган конкурста катнашуга рөхсәт (гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмалары тарафыннан бирелми).

9. Кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча белем бирү оешмасының тәкъдимнәре урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестрында күрсәтелгән һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча гына тапшырыла. Кабул итүнең контроль саннары һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча бүленгән очракта, тәкъдимнәр һөнәрләрнең, белгечлекләрнең тиешле эреләндерелгән төркемнәренә керә торган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестрында күрсәтелгән урта һөнәри белем бирү программалары булганда бирелә.

10. Конкурс гаризасы составында белем бирү оешмасы инициативасы буенча өстәмә рәвештә аңлатма язуы, эш бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре, эш бирүчеләр белән килешүләр, һөнәри квалификацияләр буенча советларның, партнер оешмаларның мөрәҗәгатьләре тапшырылырга мөмкин, әгәр аларның эшчәнлек юнәлешләре белем бирү оешмасын тәмамлаучыларны укыту гамәлгә ашырыла торган һөнәри эшчәнлек өлкәсенә туры килсә.

11. Конкурс гаризаларын бирү срогы тәмамланганнан соң кергән яисә әлеге Тәртипнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән белем бирү оешмасының конкурс гаризасы конкурста катнашуга кертелми.

12. Конкурс комиссиясе конкурс гаризаларын кабул итү срогы тәмамланганнан соң 15 декабрьдән дә соңга калмыйча конкурс гаризалары салынган конвертларны ача һәм аларны техник яктан тикшерә.

Конкурс комиссиясе конкурс гаризасында түбәндәгеләрне ачыклаган очракта, техник тикшерү йомгаклары буенча конкурс гаризасы конкурста

катнашуга кертелми:

урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестрында күрсәтелмәгән һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча тәкъдимнәр;

дәүләт аккредитациясе элек үткәрелгән урта һөнәри белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булмаган уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча тәкъдимнәр;

әлеге Тәртипнең 8 пунктында каралган документларның тулы булмаган пакетын тапшыру;

белем бирү оешмасы тарафыннан урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең гамәлдә булуын конкурс уздыру вакытына туктатып торуга китергән Россия Федерациясе законнарын бозулар;

урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты үз көчен югалткан дип танылган һөнәрләр, белгечлекләр буенча кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча тәкъдимнәр.

13. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булуын, аны туктатып тору фактының булмавын, шулай ук уку-укыту программаларына дәүләт аккредитациясен уздыру яисә элегрәк тиешле уку-укыту программалары буенча дәүләт аккредитациясен уздыру фактының булмавын раслау (дәүләт аккредитациясе булмаган белем бирү программалары өчен) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестры һәм «Дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар реестры» дәүләт мәгълүмат системасы күрсәткечләре нигезендә конкурс комиссиясе тарафыннан гаризалар салынган конвертларны ачканнан соң иң күбе биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

14. Кабул итүнең контроль саннары белем бирү оешмасы тарафыннан конкурс гаризасында күрсәтелгән тиешле һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча тәкъдимнәрдән артмаган күләмдә бүленә.

15. Белем бирү программалары буенча укыту өчен кабул итүнең контроль саннарын бүлү, кабул итүнең контроль саннары билгеләнә торган елның 20 гыйнварына кадәр исәпләнә торган тиешле һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча белем бирү оешмасының потенциалы күрсәткечләре күрсәткечләреннән чыгып, Конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү методикасы (алга таба – Методика) һәм урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча кабул итүнең контроль саннарын бүлү турында карар кабул итү критерийлары нигезендә әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә Татарстан Республикасы бюджет ассигнованиеләре исәбеннән гамәлгә ашырыла, белем бирү оешмасы эшчәнлегенең түбәндәге күрсәткечләре нигезендә:

а) штатлы педагогик хезмәткәрләрнең (укытучыларның, производствода укыту осталарының) гомуми санында гыйльми дәрәҗәсе һәм (яисә) гыйльми исеме,

һәм (яисә) югары яисә беренче квалификация категориясе булган штатлы педагогик хезмәткәрләрнең (укытучыларның, производствода укыту осталарының) өлеше;

б) профильле оешмаларда, компетенцияләрнең төбәкара үзәкләрендә стажировка узган педагогик хезмәткәрләрнең (укытучыларның, производствода белем бирү осталарының) штатлы педагогик хезмәткәрләрнең (укытучыларның, производствода белем бирү осталарының) гомуми исәбендәге өлеше;

в) урта һөнәри белем бирү программасы буенча игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча укуны тәмамлаган чыгарылыш укучыларының гомуми санына карата чыгарылыштан соң киләсе бер календарь ел чорында игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча урта һөнәри белем бирү программасы буенча укуны тәмамлаган белем бирү оешмасын тәмамлаучылар өлеше;

г) конкурска гариза бирелгән һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча республика, федераль һәм халыкара дәрәҗәдәге олимпиадаларда, конкурсларда, һөнәри осталык чемпионатларында җиңүчеләр һәм призерлар саны;

д) белем бирү оешмасы биналарын һәм бүлмәләрен игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең эреләндерелгән төркеме буенча инвалидлыгы булган һәм сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән затларны укыту өчен киртәсез мохит белән җиһазландыру;

е) игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең эреләндерелгән төркеме, белгечлекләр буенча профильле предприятие, оешма һәм (яисә) «Яшь профессионаллар (һөнәри белем бирүнең конкурентлыкка сәләтен арттыру)» федераль проектын яисә «Профессионалитет» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында компетенцияләрнең берсе буенча җиһазландырылган заманча остаханәләр белән берлектә төзелгән лабораторияләр булуы;

ж) белем бирү оешмасы җәлеп иткән бюджеттан тыш акчалар күләменең һәм белем бирү оешмасына дәүләт йөкләмәсен үтәүгә республика бюджетыннан бүлеп бирелгән бюджет акчалары күләменең нисбәте;

з) белем бирү оешмасы җәлеп иткән бюджеттан тыш акчаларның гомуми күләмендә белем бирү оешмасының матди-техник базасын үстерүгә юнәлдерелгән бюджеттан тыш акчалар өлеше;

и) конкурска игълан ителгән һөнәр, белгечлек буенча төп һөнәри белем бирү программасының, игълан ителгән һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеменең төп һөнәри белем бирү программаларының гамәлдә булу срогы кабул итүнең контроль саннары билгеләнә торган уку елы тәмамланганнан соң гына бетә торган һөнәри-иҗтимагый аккредитациягә ия булу;

к) конкурска игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме, шул исәптән компетенцияләр үзәкләре, демонстрацион имтихан уздыру үзәкләре, гамәли квалификацияләрнең күпфункцияле үзәкләре буенча заманча стандартлар һәм алдынгы технологияләр нигезендә югары квалификацияле белгечләр һәм эшче кадрлар әзерләүнең заманча инфраструктурасы булу;

л) эш бирүчеләрнең игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең,

белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча кадрлар әзерләүгә гаризалары булу;

м) конкурс уздырылганчыга кадәрге елда игълан ителгән һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча кабул итү конкурсы (бер урынга кеше);

н) конкурс уздырылганнан алдагы елда укырга кабул ителгән студентларның конкурска гариза биргән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча аттестатының уртача баллы.

16. Һөнәргә, белгечлеккә бер генә белем бирү оешмасыннан конкурс гаризасы бирелгән очракта, кабул итүнең контроль саннары бирелгән гариза нигезендә, әмма әлеге һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләме чикләрендә генә, билгеләнә.

17. Һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең барлык конкурс гаризаларының контроль саннарын билгеләү буенча тәкъдимнәрнең гомуми күләме карала торган һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләменнән артмаган очракта, конкурс комиссиясе кабул итүнең контроль саннарын конкурс гаризалары карала торган һөнәргә, белгечлеккә һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеменә конкурс гаризаларын чагыштырмыйча һәм ранжировкаламыйча билгели.

18. Конкурс комиссиясе конкурсның төп турын уздыру барышында түбәндәгеләр буенча конкурс комиссиясе утырышларын уздыра:

а) әлеге Тәртипнең 12-13 пунктлары нигезендә конкурс гаризалары булган конвертларны ачу һәм конкурс гаризаларын техник яктан тикшерү;

б) конкурс гаризалары салынган конвертларны ачкан көннән алып 15 эш көненнән дә соңга калмыйча конкурс гаризаларын бәяләү һәм чагыштыру.

19. Конкурс комиссиясе утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә торган карарлар кабул итә. Конкурс комиссиясе утырышларының беркетмәләре аларга имза салынган көннән алып бер эш көне эчендә рәсмиләштерелә.

Конкурс гаризалары белән конвертны ачу һәм конкурс гаризаларын техник яктан тикшерү нәтиҗәләре булган беркетмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш: конкурс гаризалары салынган конвертларны ачу урыны, көне, вакыты турында белешмәләр, конкурс гаризаларын биргән белем бирү оешмаларының исемлеге, конкурс гаризаларына гариза алынган дата буенча тәртип номерлары бирү турында белешмәләр, конкурс гаризалары каралган белем бирү оешмалары турында белешмәләр, әлеге Тәртипнең 12 пунктында каралган нигезне күрсәтеп, конкурста катнашуга конкурс гаризаларын кертү яисә конкурста катнаштырудан баш тарту турында карар.

Конкурс гаризаларын бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш: һәр һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме кисемтәсендә белем бирү оешмаларының конкурс гаризаларын бәяләү һәм чагыштыру нәтиҗәләре нигезендә рәтләнгән исемлеге (әлеге Тәртипнең 16 пунктында каралган очраклардан тыш), кабул итүнең контроль саннарын бүлү турында конкурс комиссиясе кабул иткән карар турында белешмәләр.

Конкурс комиссиясе беркетмәләренә, рәисне дә кертеп, утырышта катнашкан барлык конкурс комиссиясе әгъзалары имза сала, һәм беркетмәгә имза салынган көннән соң өч эш көне эчендә алар Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

20. Конкурс комиссиясе карарны гади күпчелек тавыш белән кабул итә. Тавышлар тигез булганда, комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Конкурс комиссиясе утырышта үз составындагы әгъзаларның яртысыннан артыгы булганда карар кабул итәргә хокуклы.

21. Конкурс комиссиясе, конкурс гаризасында бирелгән белешмәләрнең дөреслеген тикшерү максатыннан, белем бирү оешмалары эшчәнлеге турында мәгълүмат алу өчен вәкаләтле органнарга һәм оешмаларга сораулар җибәрергә вәкаләтле.

Кирәк булганда, конкурс комиссиясе белем бирү оешмасына бирелгән конкурс гаризасының эчтәлеген аңлату һәм андагы күрсәткечләрне төгәлләштерү турында сорату җибәрергә вәкаләтле.

Конкурс гаризасында белем бирү оешмасы тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөрес булмавын раслый торган белешмәләр алынган очракта, мондый конкурс гаризасы кире кагыла һәм бәяләнергә һәм чагыштырылырга тиеш түгел.

22. Конкурс гаризасының эчтәлеген аңлату турындагы сорату һәм аңа җавап язма рәвештә рәсмиләштерелергә тиеш. Бу вакытта конкурс комиссиясе белем бирү оешмасына сорату җибәрүне мондый соратуны җибәрү турында карар кабул ителгән көннең иртәгесендә эш көне дәвамында конкурс гаризасында белем бирү оешмасы күрсәткән адрес буенча почта элемтәсе яисә электрон почта аша тәэмин итә, ә белем бирү оешмасы күрсәтелгән соратуга җавапны аны алган көннән соңгы өч эш көне эчендә почта элемтәсе аша, утырышларын уздыру урыны буенча конкурс комиссиясенә турыдан-туры илтеп җиткерү юлы белән яисә электрон почта аша (pdf форматында соратуга җавапның сканер аша уздырылган нөсхәсен теркәп) бирүне тәэмин итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясенең конкурс гаризасының эчтәлеген аңлату турындагы соратуы һәм аңа алынган җавап конкурс гаризаларын бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсенә теркәлә.

Әгәр белем бирү оешмасы тарафыннан конкурс гаризасының эчтәлеге буенча аңлатмалар күрсәтелгән срокларда бирелмәгән булса, конкурс комиссиясе, конкурс гаризасында булган белешмәләргә нигезләнеп, карар кабул итә.

23. Кабул итүнең конкурсның төп турын уздыру нәтиҗәсендә бүленгән контроль саннары конкурс гаризаларын бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсенә имза салынган көннән алып 10 календарь көн эчендә, әмма 30 гыйнвардан да соңга калмыйча, Министрлык боерыгы белән раслана.

24. Белем бирү оешмасы кабул итүнең үзе билгеләгән контроль саннарыннан баш тартырга мөмкин. Баш тарту Министрлыкка язма рәвештә Министрлыкның рәсми сайтында конкурс гаризаларын бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсе урнаштырылган көннән алып биш календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

25. Конкурс комиссиясе мондый баш тартуны алган көннең иртәгесеннән 10 эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышын үткәрә һәм кабул итүнең

билгеләнгән контроль саннарыннан баш тарту турында беркетмә төзи.

26. Мондый баш тарту очрагында бушаган кабул итүнең контроль саннары конкурста катнашуга гаризалары кертелгән һәм техник тикшерү узган башка катнашучылар арасында яңадан бүленергә тиеш. Конкурс комиссиясе кабул итүнең бушаган контроль саннарын, белем бирү оешмаларының потенциал күрсәткечләре мәгънәләрен исәпкә алып, Методика нигезендә яңадан бүлә.

Кабул итүнең контроль саннарының бушаган күләмен тулысынча яңадан бүлү мөмкин булмаган очракта, конкурс комиссиясе әлеге Тәртипнең 28-33 пунктлары нигезендә конкурсның өстәмә турын үткәрә.

27. Кабул итүнең әлеге Тәртипнең 26 пунктында каралган контроль саннарын үзгәртү кабул итүнең билгеләнгән контроль саннарыннан баш тарту турында конкурс комиссиясе беркетмәсенә кул куелган көннән соң биш эш көне эчендә Министрлык боерыгы белән раслана.

28. Әлеге Тәртипнең 26 пунктының икенче абзацында каралган очракта, Министрлык конкурсның өстәмә туры турында белдерүдә билгеләнгән срокларда, әмма 30 марттан да соңга калмыйча, конкурсның өстәмә турын (өстәмә турларын) уздыра һәм (яисә) кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәренә үзгәрешләр кертә, түбәндәге очракларда:

а) кабул итүнең контроль саннары билгеләнгән белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру һәм (яисә) бетерү;

б) әгәр әлеге һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча бер генә конкурс гаризасы да бирелмәгән булса яисә бирелгән барлык конкурс гаризалары конкурста катнашуга кертелмәгән булса;

в) әгәр конкурс уздыру нәтиҗәсендә кабул итүнең контроль саннары тулы күләмдә бүленмәсә;

г) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы һәм (яисә) Татарстан Республикасы эш бирүчеләр берләшмәсе мөрәҗәгате белән расланган квалификацияле эшчеләргә һәм (яисә) хезмәткәрләргә һәм (яисә) урта звено белгечләренә кискен тармак ихтыяҗы барлыкка килгәндә, шул исәптән Россия Федерациясе оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең кадрлар ихтыяҗын исәпкә алып;

д) Татарстан Республикасы икътисадының тармак структурасындагы үзгәрешләр;

е) әлеге Тәртипнең 26 пунктында каралган кабул итүнең контроль саннарын тулысынча яңадан бүлү мөмкин булмаса;

ж) аерым һөнәрләр, белгечлекләр буенча урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә программалар буенча укырга алуны туктату;

з) расланган һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча аерым белем бирү оешмалары тарафыннан кабул итү үтәлмәсә.

Белем бирү оешмасы өстәмә турда катнашкан очракта, кабат конкурс гаризасы әлеге Тәртипнең 8-11 пунктларында каралган конкурс гаризаларының эчтәлегенә һәм тәртибенә охшаш тәртиптә рәсмиләштерелә. Бу очракта кабат үткәрелә торган конкурс гаризасында белем бирү оешмасының кабул итүнең бүленмәгән контроль саннары чикләрендә кабул итүнең контроль саннарын

билгеләү буенча тәкъдимнәре булырга тиеш.

Конкурсның төп турында тиешле һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча бердәнбер белем бирү оешмасы катнашкан булса һәм кабул итүнең контроль саннарын арттыруга аның язма ризалыгы булса, конкурс комиссиясе һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча конкурсның әлеге пунктта каралган өстәмә турын үткәрмичә генә кабул итүнең контроль саннарына үзгәрешләр кертә.

29. Конкурсның өстәмә турын уздырганда Министрлык үзенең рәсми сайтында конкурсның өстәмә турын уздыра башлау датасына кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча конкурсның өстәмә турын уздыру турында белдерү урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

кабат үткәрелә торган конкурс гаризаларын кабул итә башлау һәм тәмамлау датасы, урыны, сроклары;

конкурсның өстәмә турын үткәрү барышында кабул итүнең бүленә торган контроль саннары күләмнәре;

һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, урта һөнәри белем белгечлекләренең эреләндерелгән төркемнәре буенча белем бирү оешмасы өчен конкурсның өстәмә туры нәтиҗәләре буенча билгеләнергә мөмкин булган кабул итүнең контроль саннарының минималь саны;

конкурсның өстәмә турына конкурс гаризаларын карау һәм бәяләү процедурасы;

конкурсның өстәмә туры нәтиҗәләрен игълан итү һәм конкурсның өстәмә туры йомгаклары буенча кабул итүнең контроль саннарын бүлү турында Министрлык боерыгын раслау сроклары.

30. Конкурс комиссиясе конкурсның өстәмә турын уздыру барышында конкурс комиссиясе утырышларын үткәрә, аларда түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) кабат уздырыла торган конкурс гаризалары булган конвертларны кабат уздырыла торган конкурс гаризаларын кабул итү срогы тәмамланган көннән кимендә биш календарь көн узгач ачу;

б) конкурс гаризалары булган конвертларны ачкан көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге Тәртипнең 18 пунктында билгеләнгән тәртиптә конкурс гаризаларын карау һәм аларны техник яктан тикшерү;

в) әлеге Тәртипнең 18 пунктында билгеләнгән тәртиптә конкурс гаризаларына техник яктан тикшерү тәмамланган көннән алып җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, конкурс гаризаларын бәяләү һәм чагыштыру.

31. Конкурс комиссиясе утырышлары йомгаклары буенча конкурсның өстәмә турының түбәндәге беркетмәләре төзелә:

конкурс гаризалары белән конвертны ачу һәм конкурс гаризаларын техник яктан тикшерү нәтиҗәләре булган беркетмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш: конкурс гаризалары белән конвертларны ачу урыны, көне, вакыты турында белешмәләр, конкурс гаризаларын биргән белем бирү оешмаларының исемлеге, конкурс гаризаларына гариза алынган дата буенча тәртип номерлары бирү, конкурс гаризасын катнашуга кертү турында карар турында белешмәләр, өстәмә конкурс гаризалары каралган белем бирү оешмалары турында белешмәләр, әлеге Тәртипнең 12 пунктында каралган нигезне күрсәтеп, өстәмә конкурста катнашуга конкурс

гаризаларын кертү яисә конкурста катнаштырудан баш тарту турында карар;

кабат уздырыла торган конкурс гаризаларын бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсе, анда һәр һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча бәяләү һәм кабат уздырыла торган конкурс гаризаларын чагыштыру нәтиҗәләре нигезендә белем бирү оешмаларының рәтләнгән исемлеге (әлеге Тәртипнең 17 пунктында каралган очраклардан тыш), конкурсның өстәмә туры кысаларында кабул итүнең контроль саннарын бүлү турында белешмәләр булырга тиеш.

Конкурс комиссиясенең күрсәтелгән беркетмәләренә, рәисен дә кертеп, конкурс комиссиясенең шунда булган барлык әгъзалары имза сала, һәм алар, имзаланган көннән алып биш эш көне эчендә, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

32. Конкурс комиссиясе конкурсның өстәмә турын уздырганда әлеге Тәртипнең 19-22 пунктларында билгеләнгән тәртиптә карар кабул итә.

33. Конкурсның өстәмә турын уздыру йомгаклары буенча кабул итүнең билгеләнгән контроль саннарына үзгәрешләр, конкурс комиссиясе конкурс гаризаларын бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсенә кул куйган көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык боерыгы белән раслана.

Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү тәртибенә кушымта

Конкурс аша сайлап алуны уздыру һәм урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү турында карар кабул итү методикасы

1. Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджеты ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын (алга таба – кабул итүнең контроль саннары) бүлү урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һәр һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга (алга таба – белем бирү оешмалары) кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурста катнашу өчен белем бирү оешмасының конкурс гаризасында (алга таба – конкурс гаризасы) күрсәтелгән кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча тәкъдимнәрдән артмаган күләмдә бүленә.

2. Кабул итүнең контроль саннарын бүлү турында карар кабул итү критерие булып тиешле һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча белем бирү оешмасының потенциал күрсәткече (алга таба – потенциал күрсәткече) тора, ул түбәндәге таблица нигезендә билгеләнгән баллар суммасы буларак исәпләнә:

Таблица

| т/с | Потенциал күрсәткеченең атамасы | Потенциал күрсәткеченең билгеләнеше | Потенциал күрсәткечен бәяләү критерияләре | Баллар саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Штатлы педагогик хезмәткәрләрнең (укытучыларның, производствода укыту осталарының) гомуми исәбендә гыйльми дәрәҗәсе һәм (яисә) гыйльми исеме, һәм (яисә) югары яисә беренче квалификация категориясе булган штатлы педагогик хезмәткәрләрнең (укытучыларның, производствода белем бирү осталарының) өлеше (конкурсның төп яисә өстәмә турларында катнашуга белем бирү оешмасының гаризасын (алга таба – «гариза») формалаштыру датасына, процентларда). Конкурска гариза бирелгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча төп һөнәри белем бирү программасын гамәлгә ашыруда катнашучы педагогик хезмәткәрләр исәпкә алына | p1 | 85 % һәм күбрәк | 10 |
| | | | 75% алып 85% кадәр | 5 |
| | | | 75 % кимрәк | 0 |
| 2. | Штатлы педагогик хезмәткәрләрнең (укытучыларның, производствода укыту осталарының) гомуми исәбендә профильле оешмаларда, компетенцияләрнең төбәкара үзәкләрендә стажировка узган педагогик хезмәткәрләр (укытучылар, производствода белем бирү осталары) өлеше (гариза төзү көненә конкурс үткәрелә торган уку елына кадәрге өч уку елы өчен процентларда). Конкурска гариза бирелгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча төп һөнәри белем бирү программасын гамәлгә ашыруда | p2 | 70 % һәм күбрәк | 10 |
| | | | 50% башлап 70% кадәр | 5 |
| | | | 50 % кимрәк | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | катнашучы педагогик хезмәткәрләр исәпкә алына | | | |
| 3. | Урта һөнәри белем бирү программасы буенча игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча укуны тәмамлаган чыгарылыш укучыларының гомуми санына карата чыгарылыштан соң киләсе бер календарь ел чорында игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча урта һөнәри белем бирү программасы буенча укуны тәмамлаган белем бирү оешмасын тәмамлаучылар өлеше (процент); | р3 | 75 % һәм күбрәк | 10 |
| | | | 60% алып 75% кадәр | 5 |
| | | | 60 % кимрәк | 0 |
| 4. | Конкурска гариза бирелгән һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча республика, федераль һәм халыкара дәрәҗәдәге олимпиадаларда, конкурсларда, һөнәри осталык чемпионатларында җиңүчеләр һәм призерлар саны (гаризаны төзү көненә конкурс үткәрелә торган уку елына һәм конкурска кадәрге уку елына карата, берәмлекләрдә) | р4 | 4 һәм аннан күбрәк | 10 |
| | | | 2–3 | 5 |
| | | | 0–1 | 0 |
| 5. | Белем бирү оешмасы биналарын һәм бүлмәләрен игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең эреләштерелгән төркеме, инвалидлык һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар белгечлекләре буенча укыту өчен киртәсез мохит белән җиһазлау (гариза формалаштыру датасына уку корпусларында һәм тулай торакларында тиешле җиһазлар исемлеге) | р5 | әйе | 5 |
| | | | юк | 0 |
| 6. | Игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең эреләндерелгән төркеме, | р6 | әйе | 10 |
| | | | юк | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белгечлекләр буенча профильле предприятие, оешма һәм (яисә) «Яшь профессионаллар (һөнәри белем бирүнең конкурентлыкка сәләтен арттыру)» федераль проектын яисә «Профессионалитет» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында компетенцияләрнең берсе буенча җиһазландырылган заманча остаханәләр белән берлектә төзелгән лабораторияләр булуы | | | |
| 7. | Белем бирү оешмасы җәлеп иткән бюджеттан тыш акча күләменең һәм белем бирү оешмасына республика бюджетыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүгә бүлеп бирелгән бюджет акча күләменең нисбәте (конкурс уздырылганга кадәрге ике финанс елы өчен процентларда) | p7 | 15% һәм күбрәк | 10 |
| | | | 10% башлап 15% кадәр | 5 |
| | | | 10 % кимрәк | 0 |
| 8. | Белем бирү оешмасы җәлеп иткән бюджеттан тыш акчаның гомуми күләмендә белем бирү оешмасының матди-техник базасын үстерүгә юнәлдерелгән бюджеттан тыш акча өлеше (конкурс уздырылганга кадәрге ике финанс елы өчен процентларда) | p8 | 20% һәм күбрәк | 5 |
| | | | 20 % кимрәк | 0 |
| 9. | Конкурска игълан ителгән һөнәр, белгечлек буенча төп һөнәри белем бирү программасының, игълан ителгән һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеменең төп һөнәри белем бирү программаларының гамәлдә булу срогы кабул итүнең контроль саннары билгеләнә торган уку елы тәмамланганнан соң гына бетә торган һөнәри-иҗтимагый аккредитациягә ия булу (гаризаны төзү көненә раслаучы документларның таныкланган күчермәләрен теркәп) | p9 | әйе | 5 |
| | | | юк | 0 |
| 10. | Конкурска игълан ителгән һөнәр, | p10 | әйе | 10 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме, шул исәптән компетенцияләр үзәкләре, демонстрацион имтихан уздыру үзәкләре, гамәли квалификацияләрнең күпфункцияле үзәкләре буенча заманча стандартлар һәм алдынгы технологияләр нигезендә югары квалификацияле белгечләр һәм эшче кадрлар әзерләүнең заманча инфраструктурасы булу | | юк | 0 |
| 11. | Эш бирүчеләрнең билгеләнгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләштерелгән төркеме буенча кадрлар әзерләүгә гаризалары булу (күрсәткеч кадрлар әзерләүгә гариза биргән предприятиеләрдә гариза бирелгән урыннар санының конкурска гариза биргән кабул итүнең контроль цифрлары санына нисбәте буларак исәпләнә) | р11 | 0,7 һәм күбрәк | 10 |
| | | | 0,2 башлап 0,7 кадәр | 5 |
| | | | 0,2 кимрәк | 0 |
| 12. | Игълан ителгән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча конкурс уздырылганчыга кадәрге елда кабул итү (урынга кеше) конкурсы | р12 | 1,3 һәм аннан күбрәк | 10 |
| | | | 1,0 башлап 1,3 кадәр | 5 |
| | | | 1,0 кимрәк | 0 |
| 13. | Конкурс уздырылганнан алдагы елда укырга кабул ителгән студентларның конкурска гариза биргән һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча аттестатының уртача баллы | р13 | 4,5 һәм аннан күбрәк | 10 |
| | | | 3,8 башлап 4,5 кадәр | 5 |
| | | | 3,8 һәм азрак | 0 |

3. Игълан ителгән һөнәр, белгечлек, эреләндерелгән төркем буенча белем бирү оешмаларының потенциал күрсәткечләрен билгеләү нәтиҗәләре буенча белем бирү оешмаларының потенциал күрсәткечләре кимү тәртибендә тиешле һөнәр, белгечлек һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркеме буенча конкурс гаризаларын биргән белем бирү оешмаларының гомуми рейтингы төзелә.

4. Конкурс йомгаклары буенча белем бирү оешмаларының рәтләнгән

исемлегендә беренче урынны алган конкурс җиңүчесенә кабул итүнең контроль саннары билгеләнгәннән соң, җиңүченең конкурс гаризасында күрсәтелгән күләмдә кабул итүнең контроль саннарының калган күләме конкурс йомгаклары буенча белем бирү оешмаларының рәтләнгән исемлегенең икенче һәм аннан соңгы урыннарындагы белем бирү оешмалары арасында, аларның конкурс гаризаларына туры китереп, контроль саннар билгеләү юлы белән бүленә.

5. Һөнәр, белгечлек, эреләндерелгән төркем буенча потенциал күрсәткечләрен исәпләү нәтиҗәсендә берничә белем бирү оешмасының потенциал күрсәткечләренең тигез әһәмияте алынган очракта, тиешле һөнәр, белгечлек, эреләндерелгән төркем буенча кабул итүнең контроль саннары күләме (калган контроль саннар күләме) әлеге белем бирү оешмалары арасында тигез өлешләр белән бүленә, шул ук вакытта кабул итүнең контроль саннарының һәрберсе өчен бүленгән күләме оешмаларның кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча конкурс гаризасында күрсәтелгән тәкъдимнән артмаска тиеш.

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 23.10.2025 ел, № п/288 боерыгы белән расланды

## Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү буенча комиссия турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү буенча комиссия (алга таба – Конкурс комиссиясе) турында нигезләмә комиссияне төзү максатларын, төзү тәртибен, аның функцияләрен һәм аның эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән урта һөнәри белем бирү программалары буенча укыту өчен гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә ел саен уздырыла торган конкурсны оештыру һәм уздыру максатларында төзелә (алга таба – конкурс, белем бирү оешмалары).

1.3. Конкурс комиссиясе үз эшчәнлеген «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 100 статьясы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Министрлык) боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү тәртибе нигезендә гамәлгә ашыра.

1.4. Конкурс комиссиясе составына республика башкарма хакимият органнары вәкилләре керә, шулай ук иҗтимагый оешмалар, икътисадның реаль секторы вәкилләре дә кертелергә мөмкин.

Конкурста катнашучы һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләре булган конкурс комиссиясе әгъзалары мондый һөнәри белем бирү оешмаларының конкурста катнашуга гаризаларын караганда, бәяләгәндә һәм чагыштырганда Конкурс комиссиясе утырышларында катнаша алмыйлар.

Конкурс комиссиясе составына Конкурс комиссиясе рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм әгъзалары керә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны 9 кешедән ким була алмый.

## 2. Конкурс комиссиясенең функцияләре

2.1. Конкурс комиссиясе түбәндәге функцияләрне башкара:

конкурста катнашуга гаризалар салынган конвертларны ачу;

конкурста катнашуга гаризаларны карау һәм техник яктан тикшерү;

конкурста катнашуга гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру;

Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын конкурста катнашучылар арасында бүлү турында тәкъдимнәр әзерләү;

конкурс үткәрү турындагы мәгълүматтан һәркемнең файдалана алуын тәэмин итү һәм аны үткәрүнең ачыклыгын тәэмин итү;

Конкурс комиссиясе компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча белем бирү оешмалары мөрәҗәгатьләрен карау.

2.2. Конкурс комиссиясе рәисе Конкурс комиссиясе эшен оештыра, аның утырышларын алып бара һәм конкурс нәтиҗәләрен игълан итә, Конкурс комиссиясе әгъзалары тавышлары тигез булганда хәлиткеч тавыш хокукына ия.

2.3. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары Конкурс комиссиясе рәисенең, ул булмаганда, конкурсны һәм Конкурс комиссиясе утырышларын оештыру, үткәрү буенча йөкләмәләрен үти, Конкурс комиссиясе рәисе вазыйфаларын башкара.

2.4. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурста катнашуга гаризаларны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә карыйлар, бәялиләр һәм чагыштыралар.

2.5. Конкурс комиссиясе секретаре гаризалар кабул итүне, Конкурс комиссиясе соратуларын әзерләүне, эш башкаруны, Конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен алып баруны, документлар саклауны тәэмин итә.

## 3. Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру

3.1. Конкурс комиссиясе рәисе карары буенча Конкурс комиссиясе утырышларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны, конкурс турында белдерүдә билгеләнгән конкурсны үткәрү срокларын исәпкә алып, Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә.

3.2. Конкурс комиссиясе утырышында аның әгъзаларының гомуми санынnan илле процентtan артыграгы катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

3.3. Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы Конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасының бер тавышы бар. Тавышлар тигез булганда, Конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче хәлиткеч тавыш хокукына ия.

Читтән торып тавыш бирү, шулай ук Конкурс комиссиясе әгъзасының өченче затларга үз вәкаләтләрен тапшыруы рөхсәт ителми.

3.4. Конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләренә утырышта катнашкан Конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары һәм рәислек итүче имза сала.

3.5. Конкурс комиссиясе, кирәк булганда, карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдим итү характерындагы бәяләмәне алу максатында, конкурста катнашуга гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру өчен белгечләрне (экспертларны) җәлеп итә. Күрсәтелгән бәяләмә Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә теркәлә.

3.6. Конкурс комиссиясе беркетмәләрен саклау Министрлык урнашкан урын буенча гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 23.10.2025 ел, № п/288 боерыгы белән расланды

Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын бүлү буенча конкурс үткәрү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Габдрахманов Булат Фәнил улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары, комиссия рәисе |
| Карманова Марианна Радиковна | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының ИТ-бергәлеген үстерү секторы мөдире, комиссия рәисе урынбасары; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абрамов Алексей Михайлович | «Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» ДАУ ИТ-академиясе җитәкчесе; |
| Афанасьева Светлана Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге җитәкчесе; |
| Ашуралиев Тимур Мәлик улы | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе; |
| Митрофанова Любовь Александровна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри белемне үстерү бүлеге башлыгы (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Сабирова<br>Гүзәл Рәфыйк кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының ИТ-бергәлеген үстерү секторының әйдәп баручы белгече, комиссия секретаре; |
| Смага<br>Динара Фердинанд кызы | «Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ-парк» технопаркының балалар ИТ-паркы җитәкчесе |
| Тонконог<br>Софья Львовна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һөнәри белем һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге башлыгы (килешү буенча). |